*Муниципаль тур*

**Рус телендә гомуми белем бирү оешмаларының татар төркемнәрендә белем алучы укучылар өчен татар теленнән олимпиада биремнәре**

***(2017/2018 нче уку елы)***

**VII сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 180 минут**
**Максималь балл -58**

**I. Омоним сүзләрне языгыз.**

| 1 нче мәгънәсе | Омоним сүз | 2 нче мәгънәсе |
|---|---|---|
| Белдерү, таныштыру өчен язылган, әйтелгән, сөйләнгән сүз, белешмә. | ... | Җөмләнең баш кисәге. |
| Кешегә тугач та бирелә торган шәхси атама. | ... | Мөстәкыйль сүз төркеме. |
| Берәр нәрсәне белергә теләп мөрәҗәгать итү. | ... | Тыныш билгесе. |
| Тамак ярыларының сулыш ярдәмендә тирбәлүеннән барлыкка килә торган тавыш. | ... | Сөйләмнең иң кечкенә берәмлеге. |
| Көч белән, көчләп тәэсир итү, мәҗбүр итү. | ... | Сүздәге иҗекләрнең яки сөйләмдәге сүзләрнең берсен көчлерәк итеп әйтү. |

**II. Биремнәрне үтәгез.**

1. *Тукта әле, әнисе көнбагыш биргән иде бит аңа, ник әле кошкайларны сыйламаска?!* (*Н. Каштанов)* җөмләсендә ирен ассимиляциясе күзәтелгән сүзне билгеләгез.

2. *Мәһабәт кәүсәсе, юан ботаклары, тирән җыерчыклы кайрысы, үзенә генә хас яфраклары имәнне башка агачлардан аерып торалар.(Ф. Ибраһимова)* җөмләсендә рәт гармониясенә буйсынмый торган сүзне табыгыз.

3. Табышмакның җавабын табып, шул сүзгә фонетик анализ ясагыз:

*Бит-кулыңны югач,* *Мин нәрсә булам?*

*Сиңа мин кирәк.* *Әйт син тизрәк.*

4. *Теңкәгә тигән уйлардан котылу өчен, ул тагын урамга чыгып китте дә Карабай белән уйный башлады. (Н. Каштанов)* җөмләсендә бирелгән фразеологик әйтелмәне табып мәгънәсен аңлатыгыз.

5. *Өченчесендә Гөлүсә тагын да җитешсез ягымны таба, сыртыңда “бөкрең бар” дип мыскыллый. (Ф. Яхин)* җөмләсендә бирелгән тартымлы исемнәрне күрсәтегез.

6. *Озынколак төнге сәяхәтеннән кайтканда, эзен югалтыр өчен, кипкән үлән сабаклары артына сикерә. (Н. Каштанов)* җөмләсеннән затланышлы фигыльне язып алыгыз.

7. *Тик малайларның болай ябырылып килүе аларны шүрләтмәде* җөмләсендә бирелгән алмашлыкларның төркемчәләрен билгеләгез.

8. *Иң элек мин үзем моны бик тели идем, шулай ук әнием дә тели иде, аннары әтием дә риза булды. (Ә. Еники)* җөмләсендә бирелгән рәвешләрне табып, төркемчәләрен билгеләгез.

9. [wакъыт], [йумарт], [къәләм], [wәгъдә], [йәш] сүзләрен хәрефләр белән языгыз.

10. Алынма сүзләрнең татарча вариантларын языгыз: *стена, гороскоп, термин, солдат, экзамен*.

**III. “Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз” мәкаленең мәгънәсен аңлатып, 12 җөмләдән торган хикәя төзеп языгыз.**